СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2018 г. Заинск № 349

**Зәй муниципаль район Советының 2009 елның 13 апрелендәге 301 номерлы «Зәй муниципаль районының Мактаулы гражданины турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә Зәй муниципаль район Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль район Советының 2009 елның 13 апрелендәге 301 номерлы «Зәй муниципаль районының Мактаулы гражданины турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль район Советы Рәисе урынбасары В. Г. Акатьевка йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р. Г. Кәримов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы Советының
2018 нче елның 22 нче октябрендәге
350 нче номерлы Карарына
Кушымта

**Зәй муниципаль район Советының**
**2009 елның 13 апрелендәге 301 номерлы "Зәй муниципаль районының Мактаулы гражданины турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр**

Зәй муниципаль район Советының 2009 елның 13 апрелендәге 301 номерлы «Зәй муниципаль районының Мактаулы гражданины турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Нигезләмәнең II бүлегендәге 16 пунктында «Дипломы тапшырыла» сүзләреннән соң «һәм күкрәк билгесе тапшырыла» сүзләрен кертергә;
2. Нигезләмәнең II бүлегендәге 17 пунктында «Диплом» сүзеннән соң «күкрәк билгесе» сүзләрен кертергә;
3. Нигезләмәнең II бүлегендәге 17 пунктының өченче абзацында «махсус таныклыклар» сүзләреннән соң «һәм күкрәк билгесен» сүзләрен кертергә;
4. Нигезләмәнең II бүлегендәге 17 пунктының өченче абзацында «2, 3 кушымталарда» сүзләреннән соң «, 4» өстәргә;
5. Нигезләмәнең III бүлегендәге 1 пунктында «10 (ун) мең сум күләмендә "сүзләрен «11 300 (унбер мең өч йөз) күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;
6. 1 Нигезләмәнең кушымтасында:

а) 14 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«14. Кандидатура ____________________________________________
(бүләкләүгә тәкъдим ителүче затның Ф. И. О. күрсәтелә)

хезмәт коллективы җыелышы, иҗтимагый оешма, гражданин тарафыннан тәкъдим ителде ________________________________________________________________
(орган, оешма, иҗтимагый берләшмә исеме, фикер алышу датасы, протокол №)

_________________ _________________ _________________
(вазифасы) (имза) (Ф. И. О.)
М. П.

б) 15 пунктны төшереп калдырырга;

7. Нигезләмәне 4 нче кушымта белән тулыландырырга
«Зәй муниципаль районының Мактаулы гражданины» күкрәк билгесен тасвирлау (кушымта) .

Кушымта
Зәй муниципаль районының
Мактаулы гражданины турында
Нигезләмәсенә
кушымта №4

**«Зәй муниципаль районының Мактаулы гражданины»**

**күкрәк билгесен тасвирлау**

Зәй муниципаль районының Мактаулы гражданины күкрәк билгесе алтын түгәрәк рәвешендәге 40 мм диаметрлы медальне тәшкил итә. Медаль үзәгендә- Зәй муниципаль районы гербы сурәте урнашкан өстәлмә. Өстәлмәнең кыры буенча туры рельеф хәрефләр белән язулар урнаштырылган:

- югарыда - «Мактаулы гражданин»,
- түбәндә - «Зәй муниципаль районының».

Зәй муниципаль районының Мактаулы гражданины күкрәк билгесе колакчык һәм божра ярдәмендә турыпочмаклы металлдан коеп ясалган Татарстан Республикасы флагы сурәте белән тоташтырыла.

Арткы ягында киемгә беркетү өчен җайланма урнаштырыла.

Билге күкрәкнең сул ягына тагыла һәм орден-медальләр булган очракта алардан түбәнрәк урнаштырыла.